**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16.11.2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 16 ноябрендә 15:00 сәг һәм 2020 елның 16 ноябрендә 16:30 сәг уздырылган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан,көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, Кадыбаш авылында су үткәрү челтәрен ремонтлау, коены ремонтлау;
- Кадыбаш авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам яктырткычларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт килешүе буенча түләү);
- Кадыбаш авылында урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү, Кадыбаш авылында тракторлар өчен дизель ягулыгы сатып алу);
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);
- Кадыбаш авылында Подгорная урамы юлы өчен вак таш сатып алу һәм юл җәю;
- кеше яшәмәгән йортларны да кертеп, Кадыбаш авылы биналарын карап тоту буенча җирлек территориясендә төзекләндерү чаралары;
- фасадларның тышкы төрләрен төзекләндерү, биналар һәм корылмаларның коймаларын яңарту;

- Кадыбаш авылында кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы корыган агачларны кистерү;

-МТЗ-82-1 тракторы өчен гаражны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 290 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 160 кеше, бу 55,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 160 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, Кадыбаш авылында су үткәрү челтәрен ремонтлау, коены ремонтлау;

- Кадыбаш авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам яктырткычларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт килешүе буенча түләү);

- Кадыбаш авылында урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү, Кадыбаш авылында тракторлар өчен дизель ягулыгы сатып алу);

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);

- Кадыбаш авылында Подгорная урамы юлы өчен вак таш сатып алу һәм юл җәю;

- кеше яшәмәгән йортларны да кертеп, Кадыбаш авылы биналарын карап тоту буенча җирлек территориясендә төзекләндерү чаралары;

- фасадларның тышкы төрләрен төзекләндерү, биналар һәм корылмаларның коймаларын яңарту;

- Кадыбаш авылында кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы корыган агачларны кистерү;

-МТЗ-82-1 тракторы өчен гаражны ремонтлау

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Х.Л.Закиров